**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының "мондый шартнамә төзү хокукына сату нәтиҗәләре буенча Тәтеш муниципаль районы казнасындагы муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсен төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2022 елның 25 гыйнварындагы 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 25.01.2022 ел, № 32 карары белән расланган мондый шартнамә төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча Тәтеш муниципаль районы казнасындагы муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсен төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентының 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

"Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**Җитәкче** **А.А. Гасыймов**